ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

«27» апреля 2020 ел № 320

**Татарстан Республикасы “Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү Административ регламентын раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы “Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү Административ регламентын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе И.И. Игнатовка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә. Галимуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
"27" "апрель" 2020 ел, №320
карары белән
**РАСЛАНГАН**

**Татарстан Республикасы “Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү Административ регламенты**

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең Административ регламенты "Җир асты байлыклары турында" РФ Законы, Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләнде.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге административ регламент (алга таба - административ регламент) Татарстан Республикасының "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге территориясендә оештыру - хокукый формаларына һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, шулай ук физик затлар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Муниципаль контроль объекты булып Татарстан Республикасының «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә кулланыла торган барлык җир асты байлыклары тора.

1.3. Муниципаль контроль "Җир асты байлыклары турында" РФ Законы, Россия Федерациясе Җир кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-

ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезләмәләре нигезендә һәм тәртиптә гамәлгә ашырыла.

1.4.Татарстан Республикасы "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контрольне Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы башкара.

1.5. Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук гражданнар белән үзара бәйләнештә эшли.

## 2. Муниципаль контрольнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Муниципаль контрольнең максатлары булып җир законнарын бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау, шулай ук Татарстан Республикасының «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә җир асты байлыкларын рациональ, нәтиҗәле файдалануны һәм килешү йөкләмәләрен үтәүне контрольдә тоту тора.

2.2. Муниципаль контрольнең төп бурычлары булып "Җир асты байлыклары турында" РФ Законын гамәлгә ашыру, юридик, вазыйфаи һәм физик затлар тарафыннан билгеләнгән таләпләрне (нормаларны, кагыйдәләрне, нормативларны) үтәү тора.

2.3. Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы түбәндәгеләргә контрольлек итә:

1) җир асты байлыкларыннан файдалану таләпләрен үтәү;

2) аренда шартнамәләрен үз вакытында төзү һәм җир кишәрлекләренә хокукларны дәүләт теркәвенә алу;

3) юридик һәм физик затлар тарафыннан җир асты байлыкларын үзләштерүнең килешүдә билгеләнгән срокларын үтәү;

4) җир асты байлыкларыннан максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану төре буенча файдалану;

5) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын алу тәртибен үтәү;

6) билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән җир хокукын таныклаучы документлардан башка аларны үзбелдекле куллануны булдырмау;

7) җирләрне үз вакытында кире кайтару;

8) җирләрнең торышы турында дөрес белешмәләр бирү;

9) җирләрне максатчан файдалану өчен яраклы халәткә китерү яки файдалы казылма ятмаларын (гомумтаралган файдалы казылмаларны да кертеп), төзелеш, урман әзерләү, эзләнү һәм башка эшләр тәмамланганнан соң аларны рекультивацияләү буенча йөкләмәләрне үз вакытында үтәү. Шул

исәптән хуҗалык эчендәге һәм хосусый ихтыяҗлар өчен башкарыла торган эшләр;

10) аренда түләвен вакытында һәм дөрес түләү;

11) закон нигезендә билгеләнгән җир кишәрлекләрен межалау, геодезия һәм башка махсус билгеләр булдыру һәм аларның сакланышын тәэмин итү;

12) җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә закон бозуларны бетерү һәм җир законнарын үтәү;

13)җирләрдән файдалану мәсьәләләре буенча билгеләнгән йөкләмәләр нигезендә башка функцияләр.

2.4. Муниципаль контроль түбәндәге эзлеклелектә гамәлгә ашырыла:

1) тикшерүләрне планлаштыру;

2) тикшерү үткәрүгә әзерлек;

3) тикшерү үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

4) тикшерү барышында ачыкланган хокук бозу очракларына карата чаралар күрү;

5) җир законнарын бозуларны бетерүне контрольдә тоту.

### 3. Планлы тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Планлы тикшерүне үткәрү предметы булып юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм физик зат тарафыннан муниципаль хокукый актларда билгеләнгән җир законнары нормаларын һәм таләпләрне үтәү тора.

3.2. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

3.3. Планлы тикшерүләр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган еллык планнар нигезендә үткәрелә.

3.4. Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләрнең еллык планнарында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләр) исемнәре, эшчәнлекләре планлы тикшерелергә тиешле шәхси эшкуарларның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре, юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләр) яисә шәхси эшкуарлар эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыруның урнашу урыны;

2) һәр планлы тикшерүне үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерүнең башлану датасы һәм сроклары;

4) планлы тикшерүне гамәлгә ашыручы муниципаль контроль органы исеме.

3.5.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган планлы тикшерүләр планы кызыксынган затларга аны муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән яки башка мөмкин булган ысул белән җиткерелә.

3.6. Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның 1 сентябренә кадәр билгеләнгән тәртиптә "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең

хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, район прокуратурасына планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы проектын җибәрә. Планлы тикшерүләрне еллык планга кертү өчен нигезләр "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән.

3.7. Планлы тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшкуарга муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан тикшерү үткәрүгә өч эш көненнән дә соңга калмыйча, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары күрсәтмәсе яки боерыгы көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланып электрон документ әйләнеше аша һәм (яки) тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат белән хәбәр ителә яки юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына яисә башка мөмкин ысул белән җибәрелә.

3.8. Кече эшмәкәрлекнең бер субъектына карата план буенча кучмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты кече предприятие өчен елына илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

3.9. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органының күчмә планлы тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшеренүләр үткәрү зарурлыгына бәйле аерым катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшерүләр үткәрү вакыты әлеге орган җитәкчесе тарафыннан егерме эш көненә, кече предприятиеләргә карата илле сәгатьтән, микропредприятиеләргә карата унбиш сәгатьтән дә артык булмаган срокка озайтылырга мөмкин.

## 4. Планнан тыш тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибе

4.1. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләр:

1) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм (яисә) таләпләрне бозуларны бетерү турында юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү срогы тәмамлану;

1.1) юридик заттан яисә шәхси эшкуардан, әгәр юридик затка, шәхси эшкуарга тиешле планнан тыш тикшерү үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирү, рөхсәт бирү (килештерү) кагыйдәләре белән каралган булса, эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыру хокукына хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирү турында муниципаль контроль органына гариза керү;

2) муниципаль контроль органы вазыйфаи затыннан юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез хезмәттәшлек итүне тикшереп тору буенча чаралар нәтиҗәләрен анализлау буенча дәлилләнгән тәкъдимнәр керү, муниципаль контроль органнарына гражданнарның, шәхси эшкуарлар, юридик затларның мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын карау яисә алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында мөрәҗәгатьләр керү:

а) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә,

әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Россия Федерациясе архив фонды документларына, Милли китапханә фонды составына керә торган аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә куркыныч янау, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янау;

б) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Россия Федерациясе архив фонды документларына, Милли китапханә фонды составына керә торган аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы туу;

в) кулланучылар хокуклары бозылу (хокуклары бозылган граждан кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органга мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче үзенең бозылган хокукларын яклауны (торгызуны) сорап юридик затка, шәхси эшкуарга мөрәҗәгать иткән очракта һәм мондый мөрәҗәгать карап тикшерелмәгән яисә мөрәҗәгать итүченең таләпләре канәгатьләндерелмәгән булса).

Мәҗбүри таләпләрне, норматив хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куйган зат турында кирәкле мәгълүмат булмаганда, муниципаль контроль органы мәҗбүри таләпләрне, норматив хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу турында кергән мәгълүматны алдан тикшерергә мөмкин. Кергән мәгълүматны алдан тикшерү барышында мәгълүмат биргән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы карамагында булган документларын карау үткәрелә, кирәк булганда, юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән үзара бәйләнешкә кермичә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат бирү һәм муниципаль контроль органнары таләпләрен үтәү бурычларын йөкләмичә, муниципаль контроль органнары тарафыннан контроль чаралар үткәрелә. Алдан тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка документларны тапшыру мәҗбүри түгел.

4.2. Муниципаль контроль органына мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

4.3. Юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш тикшерү прокуратура органы белән килештерелгәннән соң әлеге административ регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгән нигез буенча әлеге юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча

үткәрелергә мөмкин.

4.4. Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе тарафыннан планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерыкка кул куелган көнне, муниципаль җир контроле органы көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ әйләнеше аша һәм (яки) тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат белән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары эшчәнлеген тормышка ашыру урыны буенча прокуратура органына планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза җибәрә. Бу гаризага Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесенең планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыгының күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булган документлар теркәлә.

4.5. Муниципаль контроль органы тарафыннан юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү үткәрү турында тикшерү башланганчы егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча теләсә нинди мөмкин ысул белән алдан хәбәр ителә.

## 5. Тикшерүне оештыру тәртибе

5.1. Тикшерү Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә үткәрелә. Тикшерү бары тик күрсәтмәдә билгеләнгән вазыйфаи зат яки вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

5.2. Боерык, Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының тикшерү уздыручы вазыйфаи заты тарафыннан җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка кул куйдыртып, хезмәт таныклыгын күрсәтү белән бер үк вакытта тапшырыла. Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча тикшерүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар үз вәкаләтләрен раслый торган белешмә бирергә тиеш.

5.3. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында" Федераль законның 11, 12 статьяларында каралган тәртиптә документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

5.4. Һәр тикшерүне үткәрү вакыты егерме эш көненнән дә артмаска тиеш.

## 6. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе

6.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының вазыйфаи заты тарафыннан ике нөсхәдә акт төзелә (тикшерү актының типлаштырылган формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә).

6.2. Тикшерү актына мәйданнарны үлчәү схемалары, фототаблицалар, кирәк булган очракта, җир кишәрлеген тикшерү акты, үткәрелгән экспертизалар, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне

яисә таләпләрне бозган өчен җаваплы юридик зат хезмәткәрләренең, шәхси эшкуарларның һәм физик затларның аңлатмалары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яисә аларның күчермәләре теркәлә.

6.3. Тикшерү акты тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталарның күчермәләре белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка танышу турында кул куйдырып яки тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында кул куйдырып тапшырыла. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат тикшерү акты белән танышу турында расписка бирүдән баш тартканда яки тикшерү акты белән танышудан баш тартканда, акт тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат белән җибәрелә. Хәбәрнамә шәхси эштә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) яисә муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булганда, тикшерү акты әлеге актны төзегән затның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта тикшерелә торган затка әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында, әлеге документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип санала.

6.4. Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшерүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча төзелә һәм җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә расписка яздыртып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә (тикшерелә торган затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) яисә муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булганда). Бу очракта тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яки) алуны раслаучы башка язма муниципаль контроль органы эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

6.5. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен аны прокуратура органы белән килештерү таләп ителсә, тикшерү актының күчермәсе тикшерү акты төзелгән көннән алып биш эш көне эчендә тикшерү үткәрү турында карар кабул иткән прокуратура органына җибәрелә.

## 7. Тикшерү барышында ачыкланган хокук бозулар фактларына карата муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары тарафыннан күрелә торган чаралар

7.1. Тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат тарафыннан муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне яисә таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерү үткәргән вазыйфаи затлар үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча административ чаралар күрү өчен тикшерү материалларын вәкаләтле органга җибәрергә;

2) закон бозуларны бетерү турында күрсәтмәдә билгеләнгән срокта җитешсезлекләрне бетерүне контрольдә тотарга.

## 8. Муниципаль контроль чаралары үткәргәндә җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларның хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы

8.1. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар яки аларның законлы вәкилләре муниципаль контроль буенча чаралар үткәргәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү уздырганда турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) әлеге административ регламентта һәм башка норматив хокукый актларда каралган тикшерү предметына карый торган мәгълүматны алырга;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат алар карамагында булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалардан муниципаль контроль органнары тарафыннан алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган документларны һәм (яки) мәгълүматны үз инициативасы буенча муниципаль контроль органына тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы турында, алар белән килешү яки килешмәве, шулай ук муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве турында күрсәтергә;

6) муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндә юридик затның, шәхси эшкуарның хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә;

7) тикшерүдә катнашуга Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне яисә Россия Федерациясе субъектында эшкуарлар хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне җәлеп итәргә.

8.2. Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир

хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларның бурычлары:

1) муниципаль җир контроле буенча чаралар үткәргәндә үзләренең яки вәкаләтле вәкилләренең булуын тәэмин итәргә;

2) җир кишәрлекләренә хокуклар турында документларны, проект-техник һәм башка материалларны бирергә;

3) күрсәтелгән чараларны үтәгәндә муниципаль контроль буенча чараларны оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә.

8.3. Юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар, юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре, физик затлар тикшерүләр үткәрүгә нигезсез комачаулаган һәм (яисә) тикшерүләр үткәрүдән качып йөргән һәм (яисә) билгеләнгән вакытка дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнарының муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне яисә таләпләрне бетерү турындагы күрсәтмәләрен үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## 9. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның хокуклары һәм бурычлары

9.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру бурычы йөкләнгән вазыйфаи зат үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге административ регламентта билгеләнгән тәртиптә хезмәт таныклыгын күрсәткән вакытта контроль объектларында йөрергә һәм тикшерергә;

тикшерү нәтиҗәләре буенча җир законнарын үтәүне тикшерү актлары төзергә;

муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруга комачаулаучы гамәлләрне булдырмауда яисә туктатуда, шулай ук җирләрне куллануда гаепле гражданнарның шәхесләрен билгеләүдә ярдәм сорап эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә;

бердәм дәүләт реестрыннан физик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар турында мәгълүматны һәм мөлкәтнең торышы, алардан файдалану һәм аларны саклау турында материалларны, шул исәптән муниципаль берәмлек территориясендә контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган мөлкәткә хокукларны раслаучы документларны мөстәкыйль рәвештә соратырга һәм алырга;

ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү турында мәсьәләләрне хәл итү өчен прокуратура һәм эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә;

контроль функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең дәүләт органнарына, гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне карау өчен гамәлдәге законнарны бозу турындагы материалларны җибәрергә;

Федераль салым хезмәте инспекциясенә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле барлык мәгълүматларны соратырга һәм алырга;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, Башкарма комитет структурасына керүче органнардан, милекнең барлык рәвешләрендәге оешмалардан белешмәләр һәм үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка документларны соратырга һәм алырга;

җир кишәрлекләренең торышы, алардан файдалану турында белешмәләр һәм материаллар, шул исәптән муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җиргә хокукны раслаучы документларны түләүсез алырга.

9.2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затның тикшерү уздырганда бурычлары:

1) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә;

2) Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын һәм муниципаль хокукый актларны, физик затларның, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен якларга;

3) Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесенең тикшерү үткәрү турында күрсәтмәсе нигезендә һәм анда билгеләнгәнчә тикшерү үткәрергә;

4)тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын башкару вакытында гына, күчмә тикшерүне бары тик хезмәт таныклыгын күрсәткәндә генә, Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе күрсәтмәсенең күчермәләре, әлеге административ регламентта каралган очракларда, тикшерү үткәрүне килештерү турындагы документның күчермәләрен күрсәткәндә генә үткәрергә;

5) тикшерү уздырганда җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәргәндә катнашырга һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә комачауламаска;

6) тикшерү уздырганда катнашучы җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына караган мәгълүмат һәм документлар бирергә;

7) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга.

8) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозу фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә кешеләрнең гомере, сәламәтлеге өчен, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит өчен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә,

аеручa кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе архив фонды составына кергән уникаль, аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә куркыныч янау дәрәҗәсен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр туу мөмкинлеген исәпкә алырга һәм гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның законлы мәнфәгатьләрен яклауны чикләүне булдырмаска;

10) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан шикаять белдергәндә үз гамәлләренең нигезле булуын расларга;

11) әлеге Федераль законда билгеләнгән тикшерү уздыру срокларын үтәргә;

12) юридик заттан, шәхси эшкуардан Россия Федерациясе законнарында каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәскә;

13) җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиленең үтенече буенча күчмә тикшерү уздырыр алдыннан алар нигезендә тикшерү үткәрелә торган административ регламент нигезләмәләре (булганда) белән таныштырырга;

14) юридик зат, шәхси эшмәкәрнең тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) үткәрелгән тикшерү турында язма ясарга.

9.3. Тикшерү уздырганда муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары хокуклы түгел:

1) әгәр әлеге таләпләр муниципаль контроль органы вәкаләтләренә керми икән, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

1.1) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук аларны куллану мәҗбүрилеге Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документлар таләпләрен үтәүне тикшерергә;

1.2) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

2) әлеге Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктындагы "б" пунктчасында каралган нигез буенча, шулай ук җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир биләүчеләренә һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларга тиешенчә хәбәр итү очракларында җир законнары таләпләрен үтәүне тикшерү очракларыннан тыш, аның җитәкчесе, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, планлы яисә планнан тыш күчмә тикшерүне гамәлгә ашырырга;

3) тикшерү объектлары булып тормаган яки тикшерү предметына карамаган документларны, мәгълүматны, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын бирүне таләп итәргә, шулай ук әлеге документларның оригиналларын рөхсәтсез тартып алырга;

4) үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган милли стандартларда,

үрнәкләрне, сынауларны, үлчәүләрне сайлап алу кагыйдәләрендә, техник регламентларда һәм башка норматив техник документларда тикшеренүләр, сынаулар, үлчәү кагыйдәләре һәм методлары белән билгеләнгән нормадан артып киткән күләмдә сынаулар, тикшерүләр уздыру өчен, әлеге үрнәкләрне алу турында беркетмә төземичә, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектлары һәм җитештерү тирәлеге объектлары пробаларын алырга;

5) дәүләт, коммерция, хезмәт, закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итә торган, тикшерү уздыру нәтиҗәсендә алынган мәгълүматны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

6) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттырырга;

7) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә контроль буенча чараларны алар хисабына үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирергә;

8) юридик заттан, шәхси эшкуардан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән оешмалар, башка дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы органнар карамагында булган документлар һәм (яисә) мәгълүматны, рөхсәт документларын да кертеп, бирүне таләп итәргә;

9) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән тикшерү үткәрү датасына кадәр документлар, мәгълүмат бирүне таләп итәргә. Муниципаль контроль органы, боерык яки күрсәтмә кабул ителгәннән соң, тикшерү үткәрү турында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алырга хокуклы.

## 10. Тикшерү уздырганда вазыйфаи затларның җаваплылыгы

1. Муниципаль контроль органы, аларның вазыйфаи затлары тиешле функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән, тикшерү уздырганда хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

2. Муниципаль контроль органнары вазыйфаи затларның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкаруларын контрольдә тота, вазыйфаи затларның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү очракларын исәпкә алып бара, тиешле тикшерүләр үткәрә һәм мондый вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

3. Россия Федерациясе законнарын бозуда гаеплеләргә карата кабул ителгән чаралар турында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы мондый чаралар кабул ителгәннән соң ун көн эчендә юридик затка, шәхси эшкуарга, хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган вазыйфаи затларга язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 11. Вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү

11.1. Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү турындагы гариза Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелергә тиеш.

## 12. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

12.1. Мөрәҗәгать итүчеләр вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирергә хокуклы.

12.2. Вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү турында мөрәҗәгате тора.

12.3. Шикаять бирү тәртибенә карата таләпләр:

-шикаять язмача кәгазьдә, электрон формада яки шәхси кабул итү барышында телдән тапшырыла;

-Башкарма комитет тарафыннан кабул ителгән карарларга карата шикаять Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә тапшырыла;

- Палата җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә тапшырыла;

- Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять Палата җитәкчесенә тапшырыла.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында бирелергә мөмкин.

12.4. Язма шикаять үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы орган исеме; карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме; шикаять бирүче мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны (урнашу урыны), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы; шикаять белдерелә торган карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау) турында белешмәләр;

- мөрәҗәгать итүченең карарлар, гамәлләр (гамәл кылмаулар) белән килешмәвен нигезли торган дәлилләр;

- гариза бирүченең яисә аның вәкиленең имзасы, мөһере (булганда ) һәм датасы.

Мөрәҗәгать итүче шикаятьтә бәян ителгән дәлилләрне раслаучы документлар яки аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәп бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

12.5. Мөрәҗәгать итүче шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алуга хокуклы.

12.6. Мөрәҗәгать итүченең шикаяте керү көнендә теркәлә һәм Башкарма комитетта теркәлгән көннән 15 көн эчендә карала.

12.7. Телдән кергән шикаятьнең эчтәлеге мөрәҗәгать итүченең кабул итү карточкасына языла. Әгәр телдән шикаятьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр дөрес һәм өстәмә тикшерү таләп ителми икән, шикаятькә җавап, мөрәҗәгать итүче ризалыгы белән, мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү барышында телдән бирелергә мөмкин. Калган очракларда шикаятьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә.

12.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүченең таләпләрен канәгатьләндерү яисә таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул ителә, мөрәҗәгать итүчегә карар кабул ителгән көннең алдагы көненнән дә соңга калмыйча шикаятьне карау нәтиҗәләре турында (шикаятьтә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән, почта яки электрон почта аша) дәлилләнгән җавап җибәрелә.

12.9. Әгәр язма шикаятьнең тексты укып булырлык булмаса, шикаятькә җавап бирелми, ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карау өчен җибәрелергә тиеш түгел, шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (исеме) һәм почта адресы яисә электрон почта адресы укып булырлык булса, бу хакта шикаять теркәлгән көннән биш көн эчендә хәбәр ителә.

Шикаять текстында әдәпсез яисә мәсхәрәле гыйбарәләр, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, вазыйфаи зат шикаятьне анда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалану мөмкин булмавы турында хәбәр итәргә хокуклы.

Шикаять текстында суд карарына шикаять бирү турындагы мәсьәлә куелса, шикаять мөрәҗәгать итүчегә әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, аны теркәгән көннән җиде көн эчендә кире кайтарыла.

Әгәр шикаять текстында мөрәҗәгать итүчегә элек җибәрелгән шикаятьләренә бәйле күп тапкыр язма рәвештә җаваплар бирелгән мәсьәлә язылса, һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, шикаять җибәрелгән Башкарма комитетның вазыйфаи заты, әлеге һәм элек язылган шикаятьләрнең берүк вазыйфаи затка җибәрелүе шартларында, чираттагы шикаятьнең нигезсезлеге һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Бу карар турында шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Әгәр язма шикаятьтә шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (исеме), почта адресы (урнашу урыны), җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы күрсәтелмәгән булса, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр шикаять текстында хокукка каршы гамәл әзерләнү, кылыну турында яисә хокукка каршы гамәл әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.